ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24.02.2016 Балык Бистәсе штп. № 23пи

2016 елга Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче белем бирү оешмаларының һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларының норматив чыгымнарын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге, №273-ФЗ Федераль законның 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 ноябрендәге, № 131-ФЗ Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый юнәлештәге өстәмә белем бирү мәгариф учреждениеләрен һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф учреждениеләрен финанслау нормативларын исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында " 2009 елның 31 декабрендәге №939 карары һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Расларга:

-Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биологик, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга норматив чыгымнарны;

-туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында

балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруның норматив чыгымнарына 0.5 күләмендә төзәтмә коэффициентны.

2. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына финанс-бюджет палатасын тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

- әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә балаларга өстәмә белем бирү оешмаларын финанслауны;

-әлеге карарның 1 пунктында расланган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмаларының норматив чыгымнары гамәлдә булган чор дәвамында, хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә башкарыла торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакын индексацияләү белән бергә, яңадан карауны.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

4.Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Р. Х. Хәбибуллин

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 24 февралендәге 23 пи номерлы карары белән расланган

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының туристлык-туган якны өйрәнү, экология-биология, хәрби-патриотик, социаль-педагогик, социаль-икътисадый, табигый-фәнни, техник һәм культурология юнәлешендәге балаларга өстәмә белем бирүче мәгариф оешмаларында һәм балаларга өстәмә белем бирү буенча күппрофильле мәгариф оешмаларында балаларга өстәмә белем бирү программаларын тормышка ашыруга**

**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАРЫ**

| Направление программы дополнительного образования | Территориальная дислокация | Норматив чыгымнар, бер укучыга бер елга, сум | | |
|---|---|---|---|---|
| | | беренче уку елы | икенче уку елы | өченче һәм аннан соңгы уку еллары |
| Нәфис-эстетик | шәһәр җирлеге | 3853 | 7135 | 8561 |
| | авыл җирлеге | 4228 | 7829 | 9395 |
| Физкультура-спорт | шәһәр җирлеге | 3751 | 6947 | 8337 |
| | авыл җирлеге | 4127 | 7642 | 9170 |
| Техник иҗат | шәһәр җирлеге | 4156 | 7697 | 9236 |
| | авыл җирлеге | 4531 | 8391 | 10070 |
| Туристик-туган якны өйрәнү | шәһәр җирлеге | 3954 | 7322 | 8786 |
| | авыл җирлеге | 4329 | 8017 | 9620 |
| Экологик-биологик | шәһәр җирлеге | 3954 | 7322 | 8786 |
| | авыл җирлеге | 4329 | 8017 | 9620 |
| Хәрби-патриотик | шәһәр җирлеге | 3954 | 7322 | 8786 |
| | авыл җирлеге | 4329 | 8017 | 9620 |
| Социаль-педагогик | шәһәр җирлеге | 3549 | 6572 | 7887 |
| | авыл җирлеге | 3924 | 7267 | 8720 |
| Социаль-икътисадый | шәһәр җирлеге | 3549 | 6572 | 7887 |
| | авыл җирлеге | 3924 | 7267 | 8720 |
| Табигый-фәнни | шәһәр җирлеге | 3954 | 7322 | 8786 |
| | авыл җирлеге | 4329 | 8017 | 9620 |